КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 27 ноябрь г.Казань № 1070

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы янаган хайваннар һәм үсемлекләр төрләре әйләнешенә рөхсәтләр бирү тәртибе турында» 2001 ел, 6 февраль, 57 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы янаган хайваннар һәм үсемлекләр төрләре әйләнешенә рөхсәтләр бирү тәртибе турында» 2001 ел, 6 февраль, 57 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2001 ел, 23 апрель, 221 нче, 2006 ел, 16 ноябрь, 545 нче, 2012 ел, 17 август, 714 нче, 2014 ел, 19 август, 599 нчы, 2016 ел, 26 июль, 510 нчы, 2020 ел, 18 сентябрь, 845 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «2009 елның 15 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Экология кодексының 128 статьясы белән» сүзләрен «Хайваннар дөньясы турында» 1995 елның 24 апрелендәге 52-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Экология кодексы белән» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларын ирексезләп тоту ясалма булдырылган яшәү тирәлегендә аларны саклау һәм яңадан торгызу максатларында гына, шулай ук фәнни һәм мәдәни-агарту максатларында рөхсәт ителә;

Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларын табигый мохиткә чыгару аларның табигый популяцияләрен саклап калу һәм (яисә) тулыландыру максатларында гамәлгә ашырыла.»;

түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3. Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы яный торган хайваннар һәм үсемлекләр төрләре әйләнешенә рөхсәтләр бирүне оештырырга һәм әлеге карар белән расланган Тәртип нигезендә алардан файдалануны тикшереп торуны тәэмин итәргә.»;

Әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы янаган хайваннар һәм үсемлекләр төрләре әйләнешенә рөхсәтләр бирү тәртибен яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры　　　　　　　　　　　　　　　　　　А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2001 ел, 6 февраль, 57 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 27 ноябрь, 1070 нче
карары редакциясендә)

## Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы янаган хайваннар һәм үсемлекләр төрләре әйләнешенә рөхсәтләр бирү тәртибе

### I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип «Хайваннар дөньясы турында» 1995 елның 24 апрелендәге 52-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Экология кодексы нигезендә эшләнгән.

1.2. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы янаган хайваннар һәм үсемлекләр төрләре әйләнешенә рөхсәтләр формалаштыру тәртибен билгели.

1.3. Әлеге Тәртиптә каралган таләпләр Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы яный торган хайваннар һәм үсемлекләр төрләре әйләнешенә бәйле эшчәнлекнең барлык төрләренә кагыла.

1.4. Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы яный торган хайваннар һәм үсемлекләр төрләре әйләнешен гамәлгә ашыру аларны продукциягә күчерү максатларында рөхсәт ителми.

1.5. Хайваннар дөньясы объектларын аулауны гамәлгә ашырганда Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән күләмдә дәүләт пошлинасы алына.

1.6. Яралы һәм көчсезләнгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы яный торган, Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән хайваннар төрләрен табигый әйләнә-тирә мохиттән алырга мәҗбүр булган очракта, аларның һәлакәтен булдырмау максатында әйләнешен башкару рөхсәт ителә.

1.7. Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы яный торган хайваннар һәм үсемлекләр төрләре әйләнешенә рөхсәт бирү турындагы карарны Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты (алга таба - Дәүләт комитеты) кабул итә.

### II. Рөхсәтләр бирү тәртибе

2.1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы яный торган хайваннар һәм үсемлекләр төрләренең, аларның продуктларының, өлешләренең яисә дериватларының әйләнешендә, аерым алганда, аларны Татарстан Республикасы территориясенә керткәндә һәм аннан читкә

чыгарганда, аларны аулауда, саклауда, йөрткәндә, җыйганда, карап тотканда, сатып алганда, сатканда, күчереп йөрткәндә кулланыла.

2.2. Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы яный торган хайваннарны читлектә тотуга һәм реинтродукцияләүгә рөхсәтләр бирү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карары белән билгеләнә.

2.3. Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы яный торган хайваннар һәм үсемлекләр төрләре әйләнешенә рөхсәт алу өчен (алга таба - рөхсәт), аның файдалануында хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы объектлары булган кызыксынган юридик яисә физик зат Дәүләт комитетына әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендәге форма буенча рөхсәт алуга гариза (алга таба - гариза) тапшыра.

2.4. Гаризага түбәндәгеләр теркәлә:

а) Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы яный торган хайваннар һәм үсемлекләр төрләрен тере килеш карап торучы персоналның һәм затларның һөнәри әзерлеге дәрәҗәсе турында белешмә;

б) гаризада күрсәтелгән хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы объектларыннан файдалану максатын гамәлгә ашыру кирәклеген нигезли торган документлар;

в) хайваннар дөньясы объектларына ия булу һәм аларның килеп чыгышы хокукын раслый торган документлар;

г) дәүләт пошлинасын түләүне раслый торган квитанция (хайваннар дөньясы объектларын аулау каралган очракта).

Гариза әлеге пунктның «а - б» пунктчаларында күрсәтелгән документлар булмаган очракта карауга алынмый.

2.5. Әлеге Тәртипнең 2.4 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документлар Дәүләт комитетына язма рәвештә яисә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып электрон документ рәвешендә тапшырыла, шулай ук «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша тапшырыла.

2.6. Рөхсәт хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы объектларыннан файдалану максатларының хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы объектларыннан файдалануның күздә тотыла торган срогының һәм хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы объектларының табигый мохиттән тартып алынган тоту шартларының законнарда билгеләнгән таләпләргә туры килү шарты белән Дәүләт комитеты тарафыннан бирелә.

2.7. Мөрәҗәгать итүчегә рөхсәт бирү Дәүләт комитеты гаризаны теркәгән көннән алып тугыз эш көне эчендә әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендә гамәлгә ашырыла.

Рөхсәт Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы яный торган хайваннар һәм үсемлекләр төрләре әйләнешенә рөхсәтләр бирү реестрында әлеге Тәртипкә 3 нче кушымта нигезендә теркәлә.

2.8. Мөрәҗәгать итүче рөхсәт алу өчен тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплы.

2.9. Рөхсәт - исемле документ, аны өченче затка тапшыру тыелган.

2.10. Дәүләт комитеты мөрәҗәгать итүчегә рөхсәт бирүдән баш тартуны түбәндәге очракларда тугыз эш көне эчендә җибәрә:

мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларда дөрес булмаган мәгълүмат булу;

Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы яный торган хайваннар һәм үсемлекләр төрләре әйләнеше шартларының хайваннар дөньясын саклау өлкәсендәге нормативларга һәм таләпләргә туры килмәве.

Мөрәҗәгать итүче рөхсәт бирүдән баш тарткан көннән башлап календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә аңа шикаять белдерергә хокуклы.

2.11. Дәүләт комитеты түбәндәге очракларда рөхсәтне гамәлдән чыгара:

рөхсәттә каралган шартларны бозу;

халыкның сәламәтлегенә һәм биотөрлелегенә куркыныч тудыру;

Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы яный торган хайваннар һәм үсемлекләрнең әйләнештәге төрләренең торышы начараю яисә үлеме.

Әлеге пунктның икенче - дүртенче абзацларында күрсәтелгән очракларда рөхсәтнең гамәлдә булуы Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм юкка чыгу куркынычы яный торган хайваннар һәм үсемлекләр төрләре әйләнешен гамәлгә ашыручы затка аның тарафыннан хокук бозулар һәм аларны бетерү чаралары күрелмәве турында язмача хәбәр итү вакытыннан туктатыла.